**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 20 июнь № 394

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Халык контроле» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы эшчәнлеге кысаларында Татарстан Республикасы гражданнары, дәүләт хакимияте башкарма органнары һәм җирле үзидарә органнары электрон хезмәттәшлеге турында» 2012 ел, 10 август, 676 нчы карары белән расланган «Халык контроле» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы юнәлешләре, хәбәрнамәләре категорияләре атамалары һәм категорияләре модераторлары исемлегенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Халык контроле» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы эшчәнлеге кысаларында Татарстан Республикасы гражданнары, дәүләт хакимияте башкарма органнары һәм җирле үзидарә органнары электрон хезмәттәшлеге турында» 2012 ел, 10 август, 676 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 29 июль, 528 нче; 2013 ел, 5 август, 548 нче; 2014 ел, 15 март, 156 нчы; 2014 ел, 29 ноябрь, 929 нчы; 2015 ел, 30 апрель, 308 нче; 2015 ел, 2 сентябрь, 632 нче; 2015 ел, 30 октябрь, 815 нче; 2016 ел, 12 октябрь, 741 нче; 2016 ел, 31 октябрь, 802 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «Халык контроле» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы юнәлешләре, хәбәрнамәләре категорияләре атамалары һәм категорияләре модераторлары исемлегенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| «3. | Социаль өлкә | балалар бакчалары | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы | балаларның балалар бакчаларында булуын оештыру, туклануны һәм белем бирү процессын оештыру, балалар бакчасы өчен түләү буенча ташламалар проблемалары |
| | | опека, попечительлек | | опекуннарга, попечительләргә, тәрбиягә бала алган ата-аналарга һәм ятим балаларга күрсәтелә торган социаль ярдәм чараларын күрсәтүне оештыру проблемалары |
| | | поликлиникалар һәм хастаханәләр | Татарстан Республикасы Сәламәтлек аклау министрлыгы | сәламәтлек саклау учреждениеләре эшчәнлегендә проблемалар |
| | | уңайлы мохит | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы | мөмкинлекләре чикләнгән кешеләр өчен булган чикләүләр һәм алар өчен уңайлы мохит оештыру буенча тәкъдимнәр |
| | | социаль хезмәт күрсәтү | | гражданнарга социаль хезмәт күрсәтүне оештыруда проблемалар |
| | | социаль яклау органнары тарафыннан күрсәтелә торган социаль ярдәм чаралары | | социаль ярдәм күрсәтү органнарының социаль ярдәм чараларын күрсәтүне оештыруда проблемалар |
| | | пенсия белән тәэмин итү | Россия Федерациясе Пенсия фондының Татарстан Республикасы буенча идарәсе | гражданнарны пенсия, айлык акчалата түләүләр һәм башка пособиеләр билгеләү һәм түләү мәсьәләләре буенча кабул итүне оештыруда проблемалар |
| | | социль иминиятләштерү буенча | Россия Федерациясе Социаль | социль иминиятләштерү буенча пособиеләр һәм |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | пособиеләр һәм түләүләр | иминиятләштерү фондының Татарстан Республикасы буенча төбәк бүлеге – дәүләт учреждениесе | түләүләр бирүне оештыруда проблемалар (вакытлыча эшкә яраксыз булу буенча пособие; йөклелек һәм бала табу буенча пособие; йөклелекнең башлангыч чорында исәпкә баскан хатын-кызларга бер тапкыр бирелә торган пособие; балага яшь ярым тулганчы аны карау буенча айлык пособие; бала туганда бер тапкыр түләнә торган пособие) |
| | | федераль бюджет акчасы исәбеннән тернәкләндерүнең техник чаралары һәм инвалидка (инвалид балага) күрсәтелә торган тернәкәндерү хезмәтләре | | инвалидларны, инвалид балаларны тернәкләндерүнең техник чаралары белән тәэмин итү, шулай ук тернәкләндерүнең яки инвалидны (инвалид баланы) тернәкләндерүнең индивидуаль программасын тормышка ашыру кысаларында инвалидларны, инвалид балаларны шифаханә-курорт дәвалавына җибәрү мәсьәләләре»; |

4 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| «4. | Бизнес | җәмәгать туклануы | Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы | һәркем файдалана алырлык челтәр предприятиеләре (рестораннар, барлар, кафе, кабымханәләр) тарафыннан туклану хезмәтләрен оештыруда проблемалар |
| | | сәүдә кагыйдәләрен бозу | | азык-төлек һәм азык-төлек булмаган товарлар белән сәүдә итүне оештыруда проблемалар |
| | | тышкы реклама | Монополиягә каршы федераль | гамәлдәге законнарны бозып, тышкы реклама |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча идарәсе (килешү буенча) | урнаштыру фактларын ачыклау, рекламада бастырылган мәгълүмат белән гражданнарны һәм юридик затларны ялгыштыру |
| | | этил спиртын, алкогольле һәм спиртлы продукцияне законсыз рәвештә җитештерү һәм (яки) аларның әйләнеше (ваклап сатудан тыш) | Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы (килешү буенча) | этил спиртын, алкогольле һәм спиртлы продукцияне законсыз рәвештә җитештерү һәм (яки) аларның әйләнеше (ваклап сатудан гайре) |
| | | эшкуарлар хокукларын яклау | Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил | эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыруга бәйле тәкъдимнәр һәм проблемалар»; |

8 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| «8. | Төзекләндерү һәм инфраструктура | хуҗасыз хайваннар | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе | Татарстан Республикасы торак пунктлары территориясендә хуҗасыз хайваннарны (этләр һәм мәчеләр) табу |
| | | территорияләрне төзекләндерү | Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы | ишегалларын һәм йорт яны территорияләрен төзекләндерүне оештыру буенча тәкъдимнәр, шулай ук калдыкларны күмү, чүп эшкәртү предприятиеләре төзү өчен полигоннар урнаштыру |
| | | парклар һәм скверлар | | паркларны һәм скверларны төзекләндерү, карап тоту һәм аларны эшләве буенча тәкъдимнәр («Парклар һәм скверлар» программасы кысаларында) |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | капиталь ремонт | | капиталь ремонтны сыйфатсыз итеп үткәрү |
| | | торак төзелеше | | торак төзелешенә кагылышлы мәсьәләләр»; |

11 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| «11. | Авыл хуҗалыгы | авыл хуҗалыгы | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы | авыл хуҗалыгындагы проблемалар һәм аларны бетерү буенча тәкъдимнәр, шулай ук күздә тотылган авыл хуҗалыгы предприятиеләрен урнаштыру мәсьәләләре»; |

түбәндәге эчтәлекле 19 нчы пункт өстәргә:

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| «19. | Мәшгульлек | эшсезләргә пособиеләр | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы | эшкә урнашу проблемалары һәм эшсезлек буенча пособиеләр бирүне оештыру». |

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

F:\KARAR\2017\394.docx